**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БЕЛОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

№ 50 06.02.2018 ел

Беловка авыл җирлеге Советы башлыгының 2017 елда авыл җирлегенең социаль – икътисади үсеше нәтиҗәләре һәм 2018 елга фараз турында хисабын

Беловка авыл җирлеге Советы Рәисенең 2017 елгы социаль – икътисади үсеш йомгаклары һәм 2018 елга фараз турында хисабын тыңлап һәм фикер алышып. Беловка авыл җирлеге Советы тарафыннан 2017 елда авыл җирлеге халкы мәнфәгатьләрендә эшләр башкарылган. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе законы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Советы:

1.Беловка авыл җирлеге Советы башлыгы И.Р. Мәхмүтовның 2017 елда авыл җирлегенең социаль – икътисади үсеше нәтиҗәләре һәм 2018 елга фараз турында хисабын игътибарга алырга.

2.2018 елда авыл җирлеген социаль – икътисади үстерүнең төп бурычы булып халыкның тормыш сыйфаты үсешен тәэмин итү санала.

3.Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә аерым игътибар бирергә.

4.Кредитлау һәм торак төзелеше өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган программаларның мөмкинлекләрен авылда яшьләрне ныгыту өчен максималь файдалану.

5.Халыкның тормыш дәрәҗәсен төшерүгә юл куймау һәм гражданнарның социаль хезмәтләргә тигез керү мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар күрергә.

6.Хокук саклау органнары белән берлектә җәмәгать иминлеге дәрәҗәсен күтәрү һәм җәмәгать тәртибен, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген һәм дәрәҗәсен ышанычлырак яклауны тәэмин итү буенча алга таба эш алып барырга.

7.Торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча чараларны дәвам итәргә.

8.Авыл җирлеге башкарма комитетына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә тәкъдим итәргә.

9.Авыл җирлеге Советы аппаратына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерергә.

10.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http:aksubaevo.tatarstan.ru.

11.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Беловка авыл җирлеге Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе: И.Р.Махмутов

СОВЕТ БЕЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ